**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 декабрь № 976

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 февраль, 117 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 февраль, 117 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 25 ноябрь, 929 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибе

2.1. Тышкы төзекләндерү объектларын төзәтү һәм карап тотуга финанс чыгымнары күләмнәрен исәпләгәндә РСФСР Дәүләт комитетының «РСФСРның шәһәрләрен, эшчеләр поселокларын, курорт поселокларын һәм район, авыл үзәкләрен тышкы төзекләндерү объектларын төзәтү һәм карап тоту буенча эшләрне

классификацияләү» раслау турында» 1991 ел, 24 май, 10 нчы боерыгы белән билгеләнгән эшләр төрләренә чыгымнар чагылыш таба.

Тышкы төзекләндерү объектларын төзәтү һәм карап тотуга нормалар түбәндәге документлар нигезендә билгеләнде:

ГЭСНс 81-06-01-2001 гомуми кулланылыштагы автомобиль юлларын һәм күпер корылмаларын карап тоту буенча эшләргә дәүләт элементлы смета нормалары;

ФЕР 81-02-2001-ЗД – төзелеш эшләренә федераль бердәнбер бәяләр – 33 җыентык. Электр тапшыру линияләре;

Россия юл агентлыгының 1999 ел, 30 август, 7-б номерлы боерыгы белән расланган автомобиль юлларындагы күпер корылмаларын карап тоту буенча методик тәкъдимнәр;

Россия Федерациясе Төзелеш министрлыгы Торак-коммуналь хуҗалык департаментының 1994 ел, 6 декабрь, 13 нче боерыгы белән расланган тышкы төзекләндерү предприятиеләре хезмәткәрләре хезмәтен нормалаштыру буенча тәкъдимнәр;

Россия Федерациясенең Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча дәүләт комитетының 1999 ел, 10 декабрь, 145 нче боерыгы белән расланган Яшелләндерелгән территорияләрне карап тотуның норматив-җитештерү регламенты;

Россия Федерациясе Төбәкләрне үстерү министрлыгының 2011 ел, 27 декабрь, 613 нче боерыгы белән расланган Муниципаль берәмлекләр территорияләрен төзекләндерү буенча нормалар һәм кагыйдәләр эшләү буенча методик тәкъдимнәр.

2.2. Тышкы төзекләндерү объектларын (камилләштерелгән япмалы юллар, чуерташлы һәм вак ташлы япмалы юллар, тротуарлар, күперләр, юл үткәргечләр һәм тоннельләр, парклар, скверлар (бульварлар), су саклау зоналары, юл читендәге һәм яр буйларындагы яшел массивлар, ныгытылган ярлар һәм дамбалар, яктырту челтәрләре, зиратлар, терлек каберлекләре (биотермик чокырлар), яңгыр канализацияләре, сөзәклекләрдәге газоннар һәм су сибү системалары, җир астындагы һәм җир өстендәге җәяүлеләр аркылы чыгу урыннары һәм башка объектлар) карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме муниципаль берәмлекләр күзлегеннән чыгып караганда түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\text{ОФЗ}_i = \sum_{j=1}^{19} \text{ОФЗ}_j,$$

монда:

ОФЗ – тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

i – муниципаль берәмлек;

j – тышкы төзекләндерү объекты төре.

Тышкы төзекләндерү объектлары төрләре әлеге Тәртипкә кушымтаның 1 таблицасына ярашлы рәвештә түбәндәгечә китерелгән:

$\text{ОФЗ}_1$ – камилләштерелгән япмалы (асфальт-бетон) юлларны карап тотуга финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_2$ – камилләштерелгән япмалы (асфальт-бетон) юлларны агымдагы төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_3$ – чуерташлы һәм вак ташлы япмалы юлларны карап тотуга финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_4$ – чуерташлы һәм вак ташлы япмалы юлларны агымдагы төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_5$ – тротуарларны карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_6$ – күперләр, юл үткәргечләр һәм тоннельләрне карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_7$ – су саклау зоналарын карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_8$ – ныгытылган ярларны һәм дамбаларны карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_9$ – урамнарны, юлларны һәм яр буйларын яктырту челтәрләрен карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{10}$ – урамнарны, юлларны һәм яр буйларын яктырту челтәрләре өчен электр энергиясендә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{11}$ – зиратларны һәм терлек каберлекләрен (биотермик чокырларны) карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{12}$ – яңгыр канализацияләрен карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{13}$ – сөзәклекләрдәге газоннарны һәм су сибү системаларын карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{14}$ – җир астындагы һәм җир өстендәге җәяүлеләр аркылы чыгу урыннарын (лифтсыз) карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{15}$ – җир астындагы һәм җир өстендәге җәяүлеләр аркылы чыгу урыннарын (лифтлы) карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{16}$ – паркларны карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{17}$ – скверларны (бульварларны) карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{18}$ – юл читендәге һәм яр буйларындагы яшел массивларны карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме;

$ОФЗ_{19}$ – башка корылмаларны (пляжлар, фонтаннар, һәйкәлләр һ.б.) карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме.

2.3. j төрдәге (j = 1, …, 15 өчен) тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$ОФЗ_j = V_j \times N_j \times k_1 \times k_2 \times d,$$

монда: j төрдәге тышкы төзекләндерү объектының гамәлдәге табигый характеристикалары күләме;

$N_j$ – j төрдәге тышкы төзекләндерү объектының гамәлдәге табигый характеристикалары өчен финанс чыгымнары күләмен исәпләү нормативы (әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта таблицасы);

$k_1$ – җирле исәпкә алу коэффициенты (тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм төзәтүгә уртача еллык чыгымнар нормативлары өчен авыл җирлегендә 0,9 тигез коэффициент, шәһәр тибындагы поселокта 1,0 тигез коэффициент кулланыла);

$k_2$ – шәһәр округы өчен арттыручы коэффициент (Чаллы шәһәре өчен 1 тигез, Казан өчен 1,5747 тигез);

$d$ – исәпләнә торган елга бәяләрне билгеләү өчен тышкы төзекләндерү эшләре хакын идексацияләү максатларында кулланыла торган  Федераль дәүләт статистика хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы бастырып чыгара торган кулланучылар бәяләренең җыелма индексы.

2.4. j төрдәге тышкы төзекләндерү объектларын (j = 16 – 18 өчен) карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$V_j \text{ булганда} < V_{nj}\text{: ОФЗ}_j = V_j \times N_j \times k_1 \times k_2 \times d;$$
$$V_j \text{ булганда} > V_{nj}\text{: ОФЗ}_j = V_{nj} \times N_j \times k_1 \times k_2 \times d,$$

монда:

$V_j$ – 16 – 18 төрдәге тышкы төзекләндерү объектының гамәлдәге табигый характеристикалары күләме;

$V_{nj}$ – 16 – 18 төрдәге тышкы төзекләндерү объектының гамәлдәге табигый характеристикалары күләме (әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтаның таблицасы).

2.5. j төрдәге тышкы төзекләндерү объектларын (j = 19 өчен) карап тотуга һәм төзәтүгә финанс чыгымнары күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$\text{ОФЗ}_j = S_{\text{пр}} \times P_{\text{пр}} \times k_2,$$

монда:

$S_{\text{пр}}$ – 19 төрдәге тышкы төзекләндерү объектларының торгызу бәясе;

$P_{\text{пр}}$ – 19 төрдәге тышкы төзекләндерү объектларының торгызу бәясеннән процент, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаның таблицасы нигезендә кабул ителә.»;

әлеге Тәртипкә кушымтада:

1 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1 таблица

Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм төзәтүгә уртача еллык чыгымнар нормативлары

| Т/с | Тышкы төзекләндерү объектлары төре | Тышкы төзекләндерү объектлары | Үлчәү берәмлекләре | 2015 елгы бәяләрдә норма, сум мәгънәсе | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Татарстан Республикасы муниципаль районнары өчен | Татарстан Республикасы шәһәр округлары өчен |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 1 | ОФЗ$_1$ | Камилләштерелгән япмалы (асфальт-бетон) юлларны карап тотуга финанс чыгымнары күләме | юлның 1 кв.метрына | 10,11 | 28,19 |
| 2 | ОФЗ$_2$ | Камилләштерелгән япмалы (асфальт-бетон) юлларны агымдагы төзәтүгә финанс чыгымнары күләме | | 7,73 | 12,19 |
| 3 | ОФЗ$_3$ | Чуерташлы һәм вак ташлы япмалы юлларны карап тотуга финанс чыгымнары күләме | | 3,22 | 22,11 |
| 4 | ОФЗ$_4$ | Чуерташлы һәм вак ташлы япмалы юлларны агымдагы төзәтүгә финанс чыгымнары күләме | | 1,74 | 3,52 |
| 5 | ОФЗ$_5$ | тротуарларны карап тоту һәм төзәтү | | 1,16 | 13,76 |
| 6 | ОФЗ$_6$ | Күперләр, юл үткәргечләр һәм тоннельләр | түшәмәнең 1 кв.метрына | 35,05 | 35,05 |
| 7 | ОФЗ$_7$ | Су саклау зоналары | 1 метр оынлыкка 1 кв.метр | 0,20 | 0,20 |
| 8 | ОФЗ$_8$ | Ясалма утыртмалар белән ныгытылган ярлар һәм дамбалар | 1 метр озынлыкка | 32,71 | 32,71 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | Ясалма булмаган утыртмалар белән ныгытылган ярлар һәм дамбалар | | | |
| | | Плотиналар | | | |
| 9 | ОФЗ$_{9}$ | Урамнарны юлларны һәм яр буйларын яктырту челтәрләре | челтәрләрнең 1 км | 23 040,3 | 35 141,5 |
| 10 | ОФЗ$_{10}$ | Урамнарны, юлларны һәм яр буйларын яктырту челтәрләре өчен электр энергиясе | | 35 278,9 | 48 898,7 |
| 11 | ОФЗ$_{11}$ | Зиратлар һәм терлек каберлекләре (биотермик чокырлар) | 1 гектарга | 9 829,86 | 9 829,86 |
| 12 | ОФЗ$_{12}$ | Яңгыр канализацияләре | 1 метр озынлыкка | 103,66 | 103,66 |
| 13 | ОФЗ$_{13}$ | Сөзәклекләрдәге газоннарны һәм су сибү системаларын карап тоту | 1 кв.метрга | 1,30 | 2,82 |
| 14 | ОФЗ$_{14}$ | Җир астындагы һәм җир өстендәге җәяүлеләр аркылы чыгу урыннарын (лифтсыз) карап тоту) | 1 кв.метрга | 79,85 | 79,85 |
| 15 | ОФЗ$_{15}$ | Җир астындагы һәм җир өстендәге җәяүлеләр аркылы чыгу урыннарын (лифтлы һәм яктыртылган) карап тоту | 1 кв.метрга | 121,28 | 228,04 |
| 16 | ОФЗ$_{16}$ | Парклар: | 1 кв.метрга | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 категория | | 11,19 | 11,19 |
| | | 2 категория | | 27,75 | 27,75 |
| | | 3 категория | | 23,63 | 23,63 |
| | | 4 категория | | 25,17 | 25,17 |
| | | 5 категория | | 21,11 | 21,11 |
| 17 | $ОФЗ_{17}$ | Скверлар (бульварлар): | 1 кв.метрга | | |
| | | 1 категория | | 27,10 | 27,10 |
| | | 2 категория | | 25,07 | 25,07 |
| | | 3 категория | | 23,37 | 23,37 |
| | | 4 категория | | 24,96 | 24,96 |
| | | 5 категория | | 24,97 | 24,97 |
| 18 | $ОФЗ_{18}$ | Юл читендәге һәм яр буйларындагы яшел массивлар | 1 км.га | 3 215,00 | 6 829,34 |
| 19 | $ОФЗ_{19}$ | Башка корылмалар (пляжлар, фонтаннар, һәйкәлләр һ.б.) | бүтән тышкы төзекләндерү объектлары-ның торгызу бәясеннән процентлар | 2,5 | 10»; |

әлеге кушымтага түбәндәге эчтәлекле 4 таблица өстәргә:

«4 таблица

Парклар, скверлар (бульварлар) категорияләре

(процент)

| Т/с | Категория | Агачлар | Куаклар | Газон-ар | Чәчәклек-ләр | Сукмаклар | Башкалар (биналар, фонтаннар һәм башкалар) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| I. Парклар | | | | | | | |
| 1 | 1 категория | 90 | 10 | 0 | 0 | 0 | 0 |
| 2 | 2 категория | 50 | 15 | 50 | 2 | 30 | 3 |
| 3 | 3 категория | 30 | 10 | 60 | 1 | 15 | 0 |
| 4 | 4 категория | 10 | 5 | 70 | 3 | 20 | 3 |
| 5 | 5 категория | 5 | 5 | 60 | 1 | 15 | 2 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| II. Скверлар (бульварлар) | | | | | | | |
| 1 | 1 категория | 70 | 2 | 60 | 1 | 20 | 1 |
| 2 | 2 категория | 50 | 5 | 70 | 1 | 10 | 1 |
| 3 | 3 категория | 30 | 5 | 70 | 1 | 10 | 1 |
| 4 | 4 категория | 10 | 10 | 70 | 5 | 20 | 1 |
| 5 | 5 категория | 0 | 0 | 65 | 5 | 30 | 0». |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 февраль, 117 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының тышкы төзекләндерү объектларын карап тотуга һәм ремонтлауга финанслау чыгымнары күләмнәрен хисаплап чыгару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2013 ел, 25 ноябрь, 929 нчы карары үз көчен югалтуын таныгра.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\976.docx